Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка Г.Җ. Галимҗанова шикаятенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясының; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пунктының; шулай ук тулысынча аталган карарның конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2017 елның 23 июне

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының

(2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясының; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пунктының; шулай ук тулысынча аталган карарның аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Г.Җ. Галимҗанова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Р.Г. Сәхиева мәгълүматын, яклар — гражданка Г.Җ. Галимҗанова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге мөдире И.И. Фәттахов, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының юридик бүлеге башлыгы Э.Ю. Латыйпова, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы юридик бүлегенең әйдәүче киңәшчесе Ф.М. Мөхәммәдиева, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна учреждениесе консультанты Г.Р. Нигъмәтуллина аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Р.С. Ибраһимов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинова чыгышларын тыңлап, суд утырышында тәрҗемәче — Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты Р.М. Болгарова катнашында, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Җ. Галимҗанова «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта

гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 3.7 пункты; шулай ук тулысынча аталган карар белән аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары тарафыннан кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларның текстлары рәсми рәвештә тиешле вакытлы басмаларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә басылып чыга һәм бер үк юридик көчкә ия була.

Тәртипнең 3.7 пункты техник заказчы яки махсус счет иясе капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүдә катнашучы комиссия әгъзалары таләбе буенча аларга күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү башланганчы капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышуны тәэмин итә дип күздә тота.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — күпфатирлы йорт советы рәисе урынбасары, әлеге йортта күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары буенча 2016 елның гыйнварыннан августына кадәр капиталь ремонт ясалган.

Гражданка Г.Җ. Галимҗанова Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы 2 өлеше эчтәлегеннән чыгып, капиталь ремонт үткәргәннән соң башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү актын имзалау кирәк булганын күрсәтә. Шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау бу күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре

карары нигезендә үткәрелгән очракта, күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү акты шул исәптән күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат белән килештерелергә тиеш. Ләкин, мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, капиталь ремонт тәмамлангач, капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү акты әлеге күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан имзаланмаган булган. Мондый хәл, аның фикеренчә, урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен регламентлаштыра торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән хокукый җайга салу капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышу хокукын гамәлгә ашыру механизмын үз эченә алмаганлыктан, шулай ук, әлеге комиссиядә хәлиткеч тавыш бирү хокукы булмаганга күрә, милекчеләр фикерен игътибарга алмаска мөмкинлек биргәнлектән килеп чыга.

Моннан тыш, гражданка Г.Җ. Галимҗанова Тәртипнең дәгъвалана торган 3.7 пунктын аңлатуда һәм хокукый куллануда билгесезлек булуга күрсәтә, чөнки аның эчтәлегеннән акт имзаланганчы күпме вакыт алдан комиссия әгъзалары капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышырга тиешлеге һәм күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү башланганчы капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышу ни рәвешле тәэмин ителгәне күренми.

Шулай итеп, аның фикеренчә, Тәртипнең дәгъвалана торган 3.7 пункты аның капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортта торак урын милекчесе буларак конституциячел хокукларын боза һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми.

Гражданка Г.Җ. Галимҗанова шулай ук «Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки)

күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары рәсми рәвештә татар телендә басылып чыкмаган дип саный.

Ул билгеләгәнчә, Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 статьясы буенча Татарстан Республикасында дәүләт телләре — Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә бертигез нигезләрдә кулланыла торган тигез хокуклы татар һәм рус телләре. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы дәгъвалана торган карары «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда да (PRAVO.TATARSTAN.RU) (алга таба шулай ук — рәсми портал), 2016 елның 24 июнендәге 46 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгында да Татарстан Республикасының ике дәүләт телләренең берсендә генә — рус телендә басылып чыккан дип билгели.

Шуңа бәйле рәвештә гражданка Г.Җ. Галимҗанова дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы шулай ук аның конституциячел хокукларын боза дип саный, чөнки анда күрсәтелгән норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсми рәвештә бастырып чыгаруның мәҗбүри булуы яки, конституциячел таләпкә каршы, норматив хокукый актларны бары тик бер генә дәүләт телендә бастырып чыгаруның мөмкин булуы мәсьәләсендә билгесезлек бар.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.Җ. Галимҗанова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясын; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган

Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пунктын һәм тулысынча аталган карарны аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 8, 19 (беренче өлеш), 24 (өченче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 51 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасында дәүләт телләре — тигез хокуклы татар һәм рус телләре; Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә Татарстан Республикасының дәүләт телләре бертигез нигезләрдә кулланыла; законлы рәвештә булдырган мөлкәтне биләгәндә, аннан файдаланганда, аның белән эш иткәндә милекченең хокукларын чикләү, федераль законда каралган очраклардан гайре, рөхсәт ителми; Татарстан Республикасы законнары рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш; басылып чыкмаган законнар кулланылмый; кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген нинди милләттән булуына, теленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше һәм 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм

конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала, бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә.

Шулай итеп, түбәндәгеләр әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясы;

— Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пункты; шулай ук тулысынча аталган карар аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча.

2. Россия Федерациясе Конституциясе кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауны, шулай ук мәгариф, мәдәният һәм аларның состав элементы буларак телнең гомуми мәсьәләләрен Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында булуын билгели (72 статья, 1 өлешнең «б», «е» пунктлары). Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы нигезендә Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый

актлары Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча, шулай ук Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул ителгән федераль законнарга каршы килә алмый (2 һәм 5 өлешләр).

2.1. Россия Федерациясе Конституциясе Россия Федерациясе составындагы республикаларның конституциячел-хокукый статусы, шул исәптән дәүләт буларак та, үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларның республикаларның дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә Россия Федерациясенең дәүләт теле белән беррәттән кулланыла торган үз дәүләт телләрен билгеләү хокукын таный (68 статья, 2 өлеш).

Россия Федерациясе Конституциясенең 68 статьясын конкретлаштырып, «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы Россия Федерациясе халыклары телләре турындагы Россия Федерациясе законнары Россия Федерациясе Конституциясенә, халыкара хокукның гомумтанылган принципларына һәм нормаларына һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә нигезләнгәнен һәм әлеге Законнан, федераль законнардан һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларыннан, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары законнарыннан һәм башка норматив хокукый актларыннан гыйбарәт булуын билгели (1 статьяның 1 пункты). Күрсәтелгән Закон нигезендә Россия Федерациясе субъектлары гражданнарның аралашу, тәрбия, уку-укыту һәм иҗат итү телен ирекле сайлау хокукларын яклау турында законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итәргә хокуклы (3 статьяның 3 пункты).

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын кабул иткәндә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясе Конституциясе билгеләгән Россия Федерациясе һәм аның субъектлары карамагындагы мәсьәләләрне бүлешүгә нигезләнгән һәм Татарстан

Республикасы Конституциясенең 75 статьясы (2 пункт) белән үзара бәйләнештә 29 статьясы (өченче өлеш) нигезендә үзенә караган вәкаләтен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

2.2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы законнары рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш; басылып чыкмаган законнар кулланылмый; кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый. Тиңдәш нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 15 статьясында (3 өлеш) каралган.

Әлеге конституциячел нигезләмәләргә «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» Россия Федерациясе Законының 13 статьясы тәңгәл килә, аның нигезендә республикаларның законнары һәм башка норматив хокукый актлары Россия Федерациясе дәүләт телендә рәсми рәвештә басылып чыгу белән беррәттән республикаларның дәүләт телләрендә рәсми рәвештә басылып чыга алалар (1 пункт). Шул ук вакытта федераль закон чыгаручы норматив хокукый актларны Россия Федерациясе субъектының дәүләт телендә бастырып чыгару өлешендә императив норма билгеләми, ә бу хокукны җайга салуны Россия Федерациясе субъектының үзенә калдыра.

Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар теленең кулланылышын тәэмин итү максаты белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы махсус Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, ул дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның хокукын гамәлгә ашыруга, татар тел культурасын яклауга һәм үстерүгә, татар халкы язуының тарихи традицияләрен дәвам иттерүне саклауга юнәлдерелгән.

Әлеге Татарстан Республикасы Законы нигезендә дәүләт теле буларак татар теленең статусы «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы,

башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән өлкәләрдә аны куллану мәҗбүрилеген, яклауны һәм аңа ярдәм итүне, шулай ук дәүләт теле буларак татар телен кулланугa гражданнарның хокукын тәэмин итүне күздә тота (1 статьяның 1 өлеше).

Дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары тарафыннан кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларның текстлары рәсми рәвештә тиешле вакытлы басмаларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә басылып чыга һәм бер үк юридик көчкә ия була дип күздә тота. Әлеге Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең конституциячел тигезлеге принцибы кысаларында хокукый җайга салу гавами хакимият органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы дәүләт телләренең икесендә дә басылып чыгуын күз алдында тота. Бу тәртипне үтәү мәҗбүри, чөнки ул федераль һәм республика законнары таләпләренә нигезләнгән әһәмиятле процессуаль элемент булып тора. Моны Россия Федерациясе Конституция Суды да билгели, аның хокукый позициясе эчтәлегеннән күренгәнчә, норматив хокукый актларның легальлеге аларда билгеле, законга каршы килмәгән норматив эчтәлекнең (гомуми кагыйдәнең) булуын гына таләп итмичә, тиешле законлы форманы, кабул итү һәм халыкка җиткерү тәртибен үтәүне дә күздә тота; гамәлдәге хокукый җайга салу системасында андый норматив актны суд тарафыннан тикшерү үз эченә аның норматив күрсәтмәләренең эчтәлеге, акт формасы, шулай ук аны чыгарган субъект,

кабул итү, бастыру һәм гамәлгә кертү тәртибе буенча федераль законга ярашлы булу-булмавын билгеләүне кертә (2015 елның 31 мартындагы 6-П номерлы Карар).

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы үзеннән-үзе гамәлдәге хокукый җайга салу системасында законнарның һәм башка норматив хокукый актларның бер генә дәүләт телендә басылып чыгу мөмкинлеген күздә тотмый һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 2, 8, 24 (өченче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы килми.

3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Тәртип торак законнары өлкәсенә карый, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлеш, «к» пункты) нигезендә Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы (2 һәм 5 өлешләр) буенча Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары бу өлкәдә федераль законнар нигезендә кабул ителә һәм аларга каршы килә алмый.

Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итү буенча мөнәсәбәтләрне җайга салу Россия Федерациясе Торак кодексы һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан мөстәкыйль башкарыла торган уртак карамактагы предметлар буенча (федераль бюджеттан бирелгән субвенцияләрдән тыш) Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы хисабына әлеге органнар вәкаләтенә карый (тиешенчә 13 статьяның 8.3 пункты һәм 26.3 статьяның 2 пунктындагы 61 пунктчасы). Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия

Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны вакытында үткәрүне тәэмин итүгә юнәлгән һәм шул исәптән капиталь ремонт өчен кертемнәр хисабына формалашкан акчаларның максатка ярашлы тотылуын һәм ул акчаларның сакланышы тәэмин ителүне контрольдә тоту тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар кабул итәләр (167 статьяның 1 өлеше).

Федераль законнарның әлеге нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максаты белән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, аның 3 статьясы нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында кабул итү тәртибен билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә кертелгән (1 өлешнең 9 пункты).

Димәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен раслап, федераль һәм республика законнары белән үзенә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә нигезләнгән вәкаләтен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

3.1. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы Конституциясенә шул исәптән кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча туры килү-килмәвен билгели.

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе субъекты законнарын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибен билгеләү, Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, әгәр дә башкасы гомуми яки махсус федераль закон белән расланмаган булса, Россия Федерациясе субъектының үз закон чыгару органының аерым хокукы (дискрециясе) булып тора (2005 елның 10 мартындагы 71-О номерлы Билгеләмә).

Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына. Әлеге Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы икенче өлеше нигезендә аның гамәлдә булуы кагылган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары системасына шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — республика Хөкүмәтенең норматив характердагы карарлары керә. Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын рәсми рәвештә бастырып чыгару көне итеп, карала торган Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы беренче өлешендә күрсәтелгәнчә, аларның тулы текстларын беренче тапкыр «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналында бастырып чыгару яисә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) яки «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) санала. Татарстан Республикасының күрсәтелгән норматив хокукый актлары башка язма басмаларда да бастырып чыгарыла, шулай ук телевидение һәм радио аша гомуми танышу өчен игълан ителә (халыкка җиткерелә), дәүләт

органнарына, җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга җибәрелә, элемтә каналлары аша яки башка юл белән тапшырыла ала.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясындагы 6 пункты эчтәлегеннән аңлашылганча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе Татарстан Республикасы законнары белән генә түгел, башка норматив хокукый актлары белән дә билгеләнә. Әлеге норманы гамәлгә ашыру максаты белән «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карары кабул ителгән, аның нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре имзаланганнан соң 10 көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

Димәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карала торган карары гамәлдәге хокукый җайга салу системасында, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы нигезендә, аның әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә басылып чыгарга тиеш иде.

Эш материалларыннан күренгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карары рәсми порталда 2016 елның 22 июнендә рус телендә генә урнаштырылган, татар телендә исә — 2016 елның 21 ноябрендә генә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъва белдерелгән карарының текстын рәсми порталда төрле вакытларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштыру үзеннән-үзе аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча

Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныр өчен җитәрлек нигез дип санала алмый, чөнки бу гражданнарга аларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы карала торган норматив хокукый актның эчтәлеге белән танышу мөмкинлеген тормышка ашыруда объектив рәвештә киртәләр тудырмый. Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә дә тәңгәл килә, аның нигезендә, әгәр дә норматив хокукый акт рәсми рәвештә рус телендә басылып чыккан булса, бу вакытта республика телендә аның рәсми басмасы булмау факты гражданнар хокукларын боза дип карала алмый (2012 елның 22 ноябрендәге 2157-О номерлы Билгеләмә).

Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карары аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясына (өченче өлеш) туры килә дигән нәтиҗә ясый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы дәүләт телләре булган татар һәм рус телләрендә рәсми рәвештә бастырып чыгарганда тиешле срокларны үтәүнең кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау механизмының аерылгысыз элементы булганын һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләренең икесендә дә мәгълүмат алу конституциячел-хокукый гарантияләрен тулырак һәм эзлеклерәк тәэмин итүгә ярдәм итүен күрсәтеп китүне кирәк дип саный. Шуның белән бергә норматив хокукый актның тексты, аңа кушымта итеп бирелгән актларны да исәпкә алып, тулысынча татар телендә дә, рус телендә дә рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

3.2. Күпфатирлы йортта гомуми милеккә капиталь ремонт ясау Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы беренче өлеше буенча күпфатирлы йорттагы милекчеләрнең гомуми җыелышы карары нигезендә башкарыла. Әлеге статьяның бишенче өлешендәге таләпләрдән күренгәнчә, бу

карарда капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге; капиталь ремонтка дигән чыгымнар сметасы; капиталь ремонт ясау сроклары; капиталь ремонтны финанслау чыганаклары; капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итүдә күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләре исеменнән дә катнашырга, шул исәптән тиешле актларны имзаларга вәкаләтле булган зат билгеләнергә яки расланырга тиеш. Шуның белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүне федераль законнар нормалары мондый йорттагы урыннар милекчеләренең аерым хокукы дип карый.

Россия Федерациясе Торак кодексының 182 статьясы нигезләмәләре буенча күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлгән эш алып бара торган махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма (алга таба — төбәк операторы) төбәк операторы счетында капиталь ремонт фонды оештырган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре шундый йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итә. Төбәк операторы вәкаләтләренә шул исәптән төбәк капиталь ремонт программаларын һәм (яки) аларны гамәлгә ашыру буенча кыска вакытлы планнарны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары вәкилләре, шулай ук әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затлар һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре вәкилләре катнашы белән күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү комиссиясен төзүне тәэмин итү кертелгән.

Шуның белән бергә, Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы икенче өлешеннән аңлашылганча, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсе буенча төбәк операторының акча күчерүенә күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү акты нигез булып тора. Мондый кабул итү акты җирле үзидарә органы, шулай ук күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле

зат белән килештерелгән булырга тиеш (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт шул күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре карары нигезендә үткәрелгән очракта).

Әлеге нигезләмәләрне дәвам итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәгъвалана торган Тәртип кабул ителгән, ул Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау төбәк программасы һәм, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан сайланган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау фондын формалаштыру ысулына бәйсез рәвештә, аны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнары нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итүнең гомуми кагыйдәләрен билгели, шулай ук капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү комиссиясен төзү һәм аның эшләү һәм капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул иткәндә барлыкка килә торган каршылыкларны җайга салу тәртибен регламентлаштыра.

Шулай, Тәртипнең 2 бүлегендәге нигезләмәләреннән чыгып, капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүне капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү комиссиясе (алга таба — комиссия) составын раслаучы я төбәк операторы белән төзелгән шартнамә нигезендә техник заказчы функцияләре тапшырылган затлар (капиталь ремонтлау фондын төбәк операторы счетында, счетларында формалаштырган очракта), я махсус счет ияләре (капиталь ремонтлау фондын махсус счетта формалаштырган очракта) оештыра. Комиссия составына мәҗбүри тәртиптә күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләре исеменнән капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итәргә, шул исәптән тиешле актларны имзаларга вәкаләтле зат кертелә (2.1, 2.2, 2.3 пунктлар).

Тәртиптән күренгәнчә, капиталь ремонтлау буенча эшләр тулысынча тәмамланырга 10 эш көне кала подрядчы язма рәвештә техник заказчыга һәм махсус счет иясенә эшләрнең тулы күләмдә тәмамлануы һәм капиталь

ремонтлау буенча эшләрне кабул итү кирәклеге турында хәбәр итә (3.4 пункт). Капиталь ремонтлау буенча эшләрнең кабул итүгә әзер булуы турында подрядчының язмача хәбәре нигезендә комиссия рәисе әлеге хәбәрне алган көннән соң өч эш көне эчендә күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү урынын һәм вакытын билгели һәм кабул итү датасына кимендә җиде эш көне кала комиссия әгъзаларына җиткерә (3.5 пункт). Капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсе яклары имзалаган һәм җирле үзидарә органы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика дәүләт торак күзәтчелеге вазыйфаларын башкаручы башкарма органы, төбәк операторы белән төзелгән төзелеш контролен гамәлгә ашыру шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма, күпфатирлы йорт белән идарәне гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук әгәр күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау бу күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре карары нигезендә башкарылган очракта, күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат белән килештерелгән беренчел исәп документларының КС-2 номерлы бердәм нормага китерелгән формасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү актлары, шулай ук беренчел исәп документларының КС-3 номерлы бердәм нормага китерелгән формасы буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар хакы турында белешмәләр нигезендә башкарыла.

Тәртипнең әлеге нигезләмәләренең сүзгә-сүз эчтәлеген анализлаудан, шулай ук аларның гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы урыннарын исәпкә алып, аларның максатлары белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча исемлеге күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең капиталь ремонт ясау турында гомуми җыелышы карары белән алдан расланган фактта күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү процедурасын билгеләүгә юнәлгән булулары күренә.

Моннан тыш, Тәртипнең 3.9 пунктында каралганча, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул иткән вакытта комиссия әгъзасы кабул итү актына теркәлә торган искәрмәләр яки тәкъдимнәр күрсәтеп, үзенең аерым фикерен белдерә ала. Күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүгә комиссия әгъзаларының берсе каршы килсә, алар урында барлык комиссия әгъзалары тарафыннан карап тикшерелә һәм күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү мөмкинлеге яки мондый кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителә. Комиссия кабул иткән карарларга законнар нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин (3.12 пункт).

Шуның белән дәгъвалана торган Тәртип күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә ясалган капиталь ремонтның сыйфатын бәяләүне оештыру мәсьәләсендә бөтен комиссия әгъзалары өчен дә тигез хокуклар һәм бурычлар билгели һәм комиссия әгъзаларының күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү башланганчы капиталь ремонтка башкарма һәм техник документация белән танышып чыгуы өчен сроклар буенча нинди дә булса чикләүләр эченә алмый. Күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләре исеменнән капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашырга вәкаләтле затка карата бу аңа тиешле объектта эшләрне фактта башкару моментыннан алып, шул исәптән башкарылган эшләрне күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында расланган хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге һәм күләменә туры килү-килмәвен билгеләү максаты белән техник һәм башкарма документация белән танышу хокукы гарантияләнгәнен аңлата.

Шулай итеп, Тәртипнең дәгъвалана торган 3.7 пункты Тәртипнең югарыда китерелгән нигезләмәләре, шулай ук торак законнары нормалары белән аерылгысыз норматив берлектә тора һәм үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дә конституциячел хокукларын юкка чыгармый, киметми һәм башкача бозмый һәм, димәк, Татарстан Республикасы

Конституциясенә, аның 2, 19 (беренче өлеш), 28 (беренче өлеш), 51 статьяларына каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пунктын, шулай ук тулысынча аталган карарны аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында

кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 74-П** **Татарстан Республикасы Конституция суды**